**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 16 март № 147

г. Казань

2017 – 2019 елларга Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына халыкның тормыш сыйфатын һәм аларның эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү индикаторлары буенча идарә итүгә дәүләт йөкләмәсен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән 2017 – 2019 елларга Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына халыкның тормыш сыйфатын һәм аларның эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү индикаторлары буенча идарә итүгә дәүләт йөкләмәсен (алга таба – Дәүләт йөкләмәсе) расларга.

2. Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитетына:

Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы белән берлектә, Дәүләт йөкләмәсе нигезендә «Ачык Татарстан» мәгълүмат порталының «Ведомстволар хисаплары» бердәм дәүләт хисаплылык системасында (алга таба – Система) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының хисаплары формаларына үзгәрешләр кертергә;

статистика мәгълүматларының гамәлдәге мәгънәләрен Системага кертүне, аларны актуаль хәлдә тотуны һәм Дәүләт йөкләмәсен үтәүне квартал саен мониторинглауны тәэмин итәргә.

3. Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнарына түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

Дәүләт йөкләмәсе индикаторларының гамәлдәге мәгънәләрен кертүне һәм Системада хисаплар бастыруны:

квартал индикаторлары буенча – хисап кварталыннан соң килә торган айның 20 сенә кадәр;

еллык индикаторлар буенча – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты раслый торган вакытлар нигезендә;

агымдагы елның 1 декабренә кадәр, планлаштырыла торган өч елга Дәүләт йөкләмәсен формалаштыру максатларында, Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнарына беркетелгән индикаторлар буенча агымдагы

елга мәгънәләрен һәм планлаштырыла торган өч елга чик мәгънәләрен бәяләүне Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына җибәрүне.

4. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына:

Системада хисап елына индикаторларның чик мәгънәләрен кертүне һәм аларны ел дәвамында актуальләштерүне тәэмин итәргә;

ел саен, 1 апрельгә кадәр, Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан узган ел өчен Дәүләт йөкләмәсен үтәү йомгаклары турында мәгълүматны, аның үтәлешен мониторинглау мәгълүматлары нигезендә алга таба Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты утырышында карап тикшерү өчен, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә.

5. Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгына Системадагы белешмәләрнең хисапта автомат рәвештә чагылыш табуын тәэмин итәргә.

6. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

индикаторлар үтәлешен бәяләү йомгаклары буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнарының эшчәнлек нәтиҗәлелеге индикаторларының иң югары мәгънәләренә ирешүне хуплау максатларында, Татарстан Республикасы бюджеты мөмкинлекләреннән чыгып, аларга стимул бирү турында карар кабул итәргә хокуклы;

Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан Дәүләт йөкләмәсе индикаторлары үтәлешенең процентын исәпләү Системада автомат рәвештә башкарыла;

Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан индикаторлар үтәлеше процентын исәпләү максатларында, алар барлык индикаторлар мәгънәләренә ирешкәч, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының квартал саен рейтингын формалаштырганда индикаторларның авырлыгы тигез санала;

Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан индикаторлар үтәлеше процентын исәпләү максатларында, алар барлык индикаторлар мәгънәләренә ирешкәч, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының ел йомгаклары буенча рейтингын формалаштырганда квартал индикаторларының авырлыгы – 70 процентка, ә еллык индикаторларының авырлыгы 30 процентка тигез санала;

еллык күрсәткечләрнең гамәлдәге мәгънәләре хисап чорыннан соң килә торган икенче квартал өчен мәгълүматларны бәяләгәндә исәпкә алына.

7. Хисапны бастырып чыгарган датада Дәүләт йөкләмәсе индикаторлары буенча статистика мәгълүматлары булмаган очракта, хисап формасына чираттагы хисап чорында гамәлдәге мәгънәләргә алга таба төзәтмәләр кертү белән Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органын бәяләү мәгълүматлары кертелә.

8. Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнарына бер ай эчендә индикаторлар мәгънәләрен Дәүләт йөкләмәсе индикаторлары мәгънәләренә туры китерү өлешендә дәүләт программаларына үзгәрешләр кертү турында тәкъдимнәр кертергә.

9. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип санарга:

«2016 – 2018 елларга Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына халыкның тормыш сыйфатын һәм аларның эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү индикаторлары буенча идарә итүгә дәүләт йөкләмәсен раслау турында» 2016 ел, 2 март, 129 нчы;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2016 – 2018 елларга Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына халыкның тормыш сыйфатын һәм аларның эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү индикаторлары буенча идарә итүгә дәүләт йөкләмәсен раслау турында» 2016 ел, 2 март, 129 нчы карары белән расланган 2016 – 2018 елларга Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына халыкның тормыш сыйфатын һәм аларның эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү индикаторлары буенча идарә итүгә дәүләт йөкләмәсенә үзгәрешләр кертү хакында» 2016 ел, 12 апрель, 214 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2016 – 2018 елларга Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына халыкның тормыш сыйфатын һәм аларның эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү индикаторлары буенча идарә итүгә дәүләт йөкләмәсен раслау турында» 2016 ел, 2 март, 129 нчы карары белән расланган 2016 – 2018 елларга Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына халыкның тормыш сыйфатын һәм аларның эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү индикаторлары буенча идарә итүгә дәүләт йөкләмәсенә үзгәрешләр кертү хакында» 2016 ел, 16 июль, 483 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2016 – 2018 елларга Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына халыкның тормыш сыйфатын һәм аларның эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү индикаторлары буенча идарә итүгә дәүләт йөкләмәсен раслау турында» 2016 ел, 2 март, 129 нчы карары белән расланган 2016 – 2018 елларга Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына халыкның тормыш сыйфатын һәм аларның эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү индикаторлары буенча идарә итүгә дәүләт йөкләмәсенә үзгәреш кертү хакында» 2016 ел, 16 сентябрь, 649 нчы;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2016 – 2018 елларга Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына халыкның тормыш сыйфатын һәм аларның эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү индикаторлары буенча идарә итүгә дәүләт йөкләмәсен раслау турында» 2016 ел, 2 март, 129 нчы карары белән расланган 2016 – 2018 елларга Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына халыкның тормыш сыйфатын һәм аларның эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү индикаторлары буенча идарә итүгә дәүләт йөкләмәсенә үзгәреш кертү хакында» 2016 ел, 30 декабрь, 1051 нче.

10. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков